**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул.Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР БАШЛЫГЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт,
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

2023 елның 21 марта 2 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә карар бирәм**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең ял итү, туризм һәм спорт объектлары территориаль зонасының шәһәр төзелеше регламентлары өлешендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә (Р3).

Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрендә катлар саны буенча төзелешнең биеклеге түбәндәге рөхсәт ителгән куллану төрләре буенча чикләүләрне гамәлдән чыгарырга: «иҗтимагый туклану» (код-4.6), «кунакханә хезмәте күрсәтү» (код-4.7).
Куллануның шартлы төрләрендә төзелешнең катлар саны буенча төзелешнең биеклеге түбәндәге рөхсәт ителгән куллану төрләре буенча чикләүләрне гамәлдән чыгарырга: «кибетләр» (код-4.4), «банк һәм иминият эшчәнлеге» (код-4.5).

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик иминлек мәсьәләләре буенча Лаеш шәһәре комиссиясенә йөкләргә.

**Шәһәр башлыгы** **И.Ф.Зарипов**